КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 июль г.Казань № 531

Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $138^{3}$ статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара һәм муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау хакында» 2023 елның 6 февралендәге 167 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{2.1}$ статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 июль, 531 нче
карары белән расланды

Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибе

1. Әлеге Тәртип инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләр (алга таба – килешү) төзү процедурасын билгели, ул килешүләрне әзерләү, килештерү, аларга кул кую тәртибен, килешүләр реестрын алып бару тәртибен үз эченә ала, шулай ук инфраструктураны бергәләп үстерү өчен Россия Федерациясенең башка субъектлары белән төбәкара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында төзелә торган, якларның берсе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты булган килешүләргә карата таләпләрне билгели.

2. Килешү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Россия Федерациясенең башка субъектындагы югары башкарма органы арасында төзелә һәм анда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара һәм муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау хакында» 2023 елның 6 февралендәге 167 номерлы карары белән расланган Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара һәм муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибенә карата гомуми таләпләрнең (алга таба – гомуми таләпләр) II бүлегендә каралган нигезләмәләр, шулай ук килешүнең үтәлешен координацияләү һәм якларның аны гамәлгә ашыру буенча үзара хезмәттәшлеге тәртибе бирелергә тиеш.

3. Килешү проекты әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә килешүләр проектларын эшләүгә җаваплы республика башкарма хакимият органы тарафыннан эшләнелә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Россия Федерациясенең башка субъектындагы югары башкарма органы белән килешү төзү турындагы килешүләр проектларын эшләүгә җаваплы республика башкарма хакимият органының тәкъдиме, килешү проекты белән бергә, Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

5. Килешү проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карала һәм, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының килешү проектына карата искәрмәләре булганда, килешү проектын төзегән республика башкарма хакимият органы тарафыннан эшләп бетерелә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килешү проекты килештерелгәннән соң, килешүгә кул кую датасы һәм урыны билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча килешүләрнең үтәлешен координацияләү функцияләре Татарстан Республикасына йөкләнгән һәм төзелгән килешүләрнең реестрын алып бара.

8. Килешүне реестрга кертү турында гариза, шулай ук килешү текстының

күчермәләрен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җибәрү, кул куелган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, килешү проектын эшләгән республика башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Реестрга кертелгән килешүләрнең үтәлү барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җибәрү килешү проектын эшләгән республика башкарма хакимият органы тарафыннан квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның бишенче эш көненнән соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25еннән дә соңга калмыйча, гомуми таләпләргә теркәлгән 1 кушымта нигезендәге форма буенча килешүләрнең үтәлешен координацияләү функцияләре Татарстан Республикасына йөкләнгән килешүләрнең үтәлү барышы турындагы белешмәләрне, реестрдагы күрсәткечләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Инфраструктураны бергәләп<br>үстерү өчен төбәкара<br>хезмәттәшлек турында<br>килешүләр төзү тәртибенә<br>1 нче кушымта

Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен<br>төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләр проектларын эшләүгә<br>җаваплы республика башкарма хакимият органнары<br>исемлеге

| Республика башкарма хакимият органы | Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләр объектлары |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | сәламәтлек саклау объектлары |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | мәдәният объектлары; социаль-мәдәни билгеләнештәге башка объектлар |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | мәгариф оешмалары һәм мәгариф өлкәсендә башка дәүләт оешмалары урнашкан социаль инфраструктура объектлары |
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | электр энергиясен җитештерү, тапшыру һәм бүлү объектлары; торба үткәргеч транспорт объектлары; газ белән тәэмин итү объектлары |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга нигезләнеп билгеләнгән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, беренчел һәм (яисә) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртү, саклау объектлары |
| Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | спорт объектлары |
| Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | җылылык белән тәэмин итү объектлары, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яки) су чыгаруның үзәкләштерелгән системалары, мондый системаларның кайбер объектлары; коммуналь инфраструктура объектлары яки «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 10, 11 һәм 17 пунктларында күрсәтелмәгән коммуналь инфраструктура объектлары, каты коммуналь калдыкларны |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | эшкәртү, туплау, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру гамәлгә ашырыла торган объектлар |
| Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | транспорт инфраструктурасы объектлары, юл эшчәнлеге объектлары |
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | халыкка социаль хезмәт күрсәтү объектлары |
| Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | Электрон исәпләү машиналары өчен программалар (ЭВМ өчен программалар), мәгълүмат базалары, мәгълүмат системалары (шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары) һәм (яки) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар яки составына ЭВМ өчен программалар һәм (яки) мәгълүмат базалары керә торган башка мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, яисә әлеге объектларның җыелмасы (алга таба – мәгълүмат технологияләре объектлары), яисә мәгълүмат технологияләре объектлары һәм бер яисә берничә шундый объект белән технологик бәйле һәм аларның эшләвен тәэмин итү яисә концессион килешүдә каралган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт (алга таба – мәгълүмат технологияләре объектлары эшчәнлеген тәэмин итүнең техник чаралары); мәгълүмат технологияләре объектлары белән технологик бәйле күчемле мөлкәт белән бердәм билгеләнү белән берләштерелгән һәм мәгълүматны формалаштыру, саклау, эшкәртү, кабул итү, тапшыру, илтеп җиткерү, аңа үтеп керүне, аның күзаллавын һәм таралуын тәэмин итү процессларының мәгълүмат базаларын һәм ЭВМ өчен программаларны файдаланып автоматлаштыру өчен билгеләнгән биналар, биналарның бер өлеше яки бүлмәләр җыелмасы (мәгълүматларны эшкәртү үзәкләре) |
| Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | гражданнарның ялын һәм туризмны оештыру өчен кулланыла торган объектлар |

---

Инфраструктураны бергәләп
үстерү өчен төбәкара
хезмәттәшлек турында
килешүләр төзү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен
төбәкара хезмәттәшлек турында төзелгән
килешүләр реестры

| Т/с | Килешү номеры һәм кул кую датасы | Килешү яклары | Килешүнең гамәлдә булу чоры | Инфраструктура объектлары турында белешмәләр, хәзерге хокук ияләрен күрсәтеп, аларның статусы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |

Инфраструктураны бергәләп
үстерү өчен төбәкара
хезмәттәшлек турында
килешүләр төзү тәртибенә
3 нче кушымта

Форма

20____ елның _____ кварталы өчен
_____________ һәм _____________ арасында төзелгән төбәкара хезмәттәшлек турында килешүләрне үтәү барышы турында
белешмәләр

I. Төбәкара хезмәттәшлек турында килешү буенча гомуми белешмәләр
(төбәкара хезмәттәшлек турында һәр килешү буенча тутырыла)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | ________ номерлы төбәкара хезмәттәшлек турында килешү | |
| 1.1. | Төбәкара хезмәттәшлек турында килешү датасы һәм номеры | |
| 1.2. | Төбәкара хезмәттәшлек турында килешүнең гамәлдә булу срогы | |
| 1.3. | Россия Федерациясе субъектларының югары башкарма органнары – төбәкара хезмәттәшлек турында килешү яклары исемнәре | |
| 1.4. | Төбәкара хезмәттәшлек турында килешүнең предметы | |
| 1.5. | Төбәкара хезмәттәшлек турында килешүнең максаты | |
| 1.6. | Төбәкара хезмәттәшлек турында килешүнең үтәлешен координацияләү функцияләре йөкләнә торган Россия Федерациясе субъекты исеме | |
| 1.7. | Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектының төбәкара хезмәттәшлек турында килешүне гамәлгә ашыру барышында, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты билгеләгән җайга салына торган тарифлар буенча хезмәт күрсәтү өлешендә якларның үзара мөнәсәбәтләрен, шулай ук «горизонталь» субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлары турында мәгълүмат | |
| 1.8. | Төбәкара хезмәттәшлек турында килешүне вакытыннан алда өзү нигезләре | |
| 1.9. | Инфраструктураны бергәләп үстерү нәтиҗәләренә ирешү | |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча йөкләмәләр | |

II. Инфраструктура объектлары характеристикалары (һәр объект буенча тутырыла)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | 1 нче объект | |
| 1.1. | Инфраструктура объектының исеме (кыскартылган исеме) | |
| 1.2. | Инфраструктура объекты заказчысы, шулай ук инфраструктура объектын төзү (реконструкцияләү) вакытына җир кишәрлекләренә хокукларны һәм чикләүләр турында мәгълүмат | |
| 1.3. | Инфраструктура объекты исеме | |
| 1.4. | Инфраструктура төре | |
| 1.5. | Эшләр төрләре | |
| 1.6. | Объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итү, аны дәүләт теркәвенә алу, коммуналь инфраструктурага тоташтыруны тәэмин итү өчен җаваплы | |
| 1.7. | Төзелешне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру һәм башкарылган эшләрне кабул итү өчен җаваплы | |
| 1.8. | Гамәлгә ашыру сроклары: | |
| 1.8.1. | башлану датасы: план/факт | |
| 1.8.2. | төгәлләнү датасы: план/факт | |
| 1.9. | Статистика хисаплылыгының күрсәткечләре, шулай ук башка, шул исәптән төбәкара хезмәттәшлек турындагы килешүдә каралган инфраструктура объектын тасвирлый торган башка күрсәткечләр | |

III. Инфраструктура объектларын финанс белән тәэмин итү турында белешмәләр (мең сум) (һәр объект буенча тутырыла)

| 2. | 1 нче объектны финанс белән тәэмин итү турында белешмәләр | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | ... | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1. | Инфраструктура объектын финанслауның гомуми күләме, шул исәптән: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап датасына | | | | | |
| 2.1.1. | Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре күләме: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |
| | хисап датасына | | | | | |
| 2.1.2. | Россия Федерациясе субъекты бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |
| | хисап датасына | | | | | |
| 2.1.3. | «Горизонталь» субсидия күләме: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |
| | хисап датасына | | | | | |
| 2.1.4. | Муниципаль берәмлек бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |
| | хисап датасына | | | | | |
| 2.1.5. | бюджеттан тыш финанслау чыганаклары: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |
| | хисап датасына | | | | | |
| 2.1.6. | Башка финанслау чыганаклары: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |
| | хисап датасына | | | | | |
| Инфраструктура объектын тотуга чыгымнар турында белешмәләр | | | | | | |
| 2.2. | Инфраструктура объектын эксплуатацияләү стадиясендә чыгымнар: | | | | | |
| | төбәкара хезмәттәшлек турында килешүдә каралган | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хисап датасына | | | | | |

Республика башкарма хакимият органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары)

______________ ______________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

20__ ел, «__» ___________

Башкаручы: _____________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

Телефоны: ____________________________.

_____________________________